**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.10.2020 № 1068

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль хезмәткәренә, муниципаль вазыйфа биләүче затка тиешле еллар эшләгән өчен дәүләт яки муниципаль пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында « 2009 елның 22 декабрендәге 1025 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» (2016 елның 04 апрелендәге 220 номерлы, 2018 елның 14 маендагы 399 номерлы үзгәрешләрне исәпкә алып)

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 22 декабрендәге 1025 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль вазыйфасын биләүче затка, тиешле еллар эшләгән өчен дәүләт яки муниципаль пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба-нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктта түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәттән (алга таба муниципаль хезмәт) эштән азат ителгәндә муниципаль хезмәткәргә, тиешле еллар эшләгән өчен дәүләт яисә муниципаль пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә, эштән азат ителгән көнгә биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча аның айлык акчалата түләвенең биш мәртәбә күләменә, дәүләт яисә муниципаль хезмәтнең 1 нче таблицасы нигезендә һәм аннан соңгы тулы елында өстәмә 0,5 акчалата түләү стажы булса да, муниципаль хезмәткәрнең акчалата хезмәт хакының кимендә ун күләменнән арттырып түләнә. Муниципаль хезмәт стажы муниципаль хезмәттән киткән көнгә билгеләнә.

*1 таблица*

| Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү елы | Тиешле ел эшләгән өчен пенсия билгеләү стажы |
|---|---|
| 2018 ел | 16 ел |
| 2019 ел | 16 ел 6 ай |
| 2020 ел | 17 ел |
| 2021 ел | 17 ел 6 ай |
| 2022 ел | 18 ел |
| 2023 ел | 18 ел 6 ай |
| 2024 ел | 19 ел |
| 2025 ел | 19 ел 6 ай |
| 2026 һәм аннан соңгы еллар | 20 ел |

Тиешле еллар эшләгән өчен дәүләт яисә муниципаль пенсиягә чыкканда муниципаль хезмәттән картлык буенча хезмәт пенсиясе алуга хокук бирә торган яшькә җиткәч яисә «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» 2001 елның 17 декабрендәге 173-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидлык буенча пенсия билгеләү хокукы бирә торган яшькә җиткәч, муниципаль хезмәттән китүдән тыш һәм тиешле еллар эшләгән өчен дәүләт яисә муниципаль пенсия алу өчен кирәкле муниципаль хезмәт стажы булганда китү күздә тотыла.»

1.2.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бер мәртәбә бүләкләү күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган айлык акчалата түләү составына муниципаль хезмәткәр өчен түбәндәгеләр керә:

- вазыйфаи оклад,
-класс чины өчен оклад;
- муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү.

Муниципаль вазыйфаи затны бер мәртәбә бүләкләү күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган айлык акчалата түләү составына түбәндәгеләр керә:

- айлык акчалата бүләкләү(ежемесячное денежное вознаграждение),
- айлык акчалата бүләкләү(ежемесячное денежное поощрение)».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча урынбасары М.Х.Хабибуллловага йөкләргә.

Җитәкче Р.М.Заһидуллин